МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.11.2016 г. Казань № под-2245/16

**Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә раслау турында» 2016 елның 22 ноябрендәге под-2245/16 номерлы боерыгы**

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы указы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә кандидатлар сайлауны сыйфатлы башкару һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында нәтиҗәле кадрлар резервы формалаштыру максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында кушымтада бирелгән нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында» 2014 елның 30 маендагы 3122/14 номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Татарстан Республикасы Премьер министры
урынбасары – министр Э.Н.Фәттахов

ТР Юстиция министрлыгында 2016 елның 23 декабрендә теркәлде.
Теркәлү номеры – 3766

**Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә (ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016 елның 22 ноябрендәге под-2245/16 номерлы боерыгы белән расланды)**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс (алга таба – конкурс) үткәрүнең тәртибен, шартларын һәм методикасын билгели.

Конкурс Россия Федерациясе гражданнарының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә (алга таба – граждан хезмәте) тигез дәрәҗәдә үтеп керүенең конституциячел хокукын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – граждан хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукын тәэмин итә.

1.2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында (алга таба – Министрлык) конкурс «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законның 22 статьясы, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы указы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмә раслау турында» 2011 елның 14 мартындагы ПУ-127 номерлы указы нигезендә уздырыла.

Конкурс Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасын) биләү өчен дәгъва белдерүчеләрнең һөнәри дәрәҗәсен, аларның әлеге вазыйфага карата билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.3. Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә граждан хезмәтенең конкурс

нигезендә биләнә торган вакантлы вазыйфасы булганда Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба – Министр) карары нигезендә игълан ителә.

Конкурс уздыру турында карар Министр тарафыннан структур бүлекчә җитәкчесе әзерләгән дәлилле язма гариза нигезендә кабул ителә.

Гаризада, конкурс игълан итү турында тәкъдим белән беррәттән, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасының (алга таба – граждан хезмәте вазыйфасының) аталышы һәм, вазыйфаи бурычларның үзенчәлекләрен исәпкә алып, бу вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләре (шушы Нигезләмәгә 1 нче кушымта) булырга тиеш.

1.4. Министрлыкта дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелми:

«җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категорияләрендәге граждан хезмәте вазыйфасы вәкаләтләрен билгеле бер чорга биләү өчен билгеләнгәндә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели һәм азат итә торган «җитәкчеләр» категориясендәге граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә;

вакытлы хезмәт контракты төзелгәндә;

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законның 28 статьясының 2 өлешендә, 31 статьясының 1 өлешендә һәм 60.1 статьясының 9 өлешендә каралган очракларда граждан хезмәткәрен граждан хезмәтенең башка вазыйфасына билгеләгәндә;

граждан хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән граждан хезмәткәрен (гражданинны) граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.

1.5. Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелмәскә мөмкин:

граждан хезмәтенең алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, Министрлык боерыгы нигезендә расланучы вазыйфалар исемлегендәге аерым вазыйфаларына билгеләгәндә;

Министр карары нигезендә, граждан хезмәтенең кече вазыйфалар төркеменә карый торган граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә.

1.6. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

сәләтләре һәм һөнәри әзерлеге нигезендә граждан хезмәтенә тигез дәрәҗәдә үтеп керүдә Россия Федерациясе гражданнарының конституциячел хокукларын, шулай ук граждан хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукларын тәэмин итү;

граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен аеруча туры килә торган кандидатларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм конкурста катнашуга кертелгән кандидатлар арасыннан сайлап алу;

граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен Министрлыкның кадрлар резервын формалаштыру.

1.7. Конкурсларны үткәргәндә хәл ителә торган мәсьәләләр:

барлык кандидатлар өчен дә алар тарафыннан конкурс биремнәре һәм

процедуралары үткәндә тигез шартларны тәэмин итү;

кандидатларны граждан хезмәте культурасына, һөнәри вәкаләтлелеккә һәм шәхси-эшлекле сыйфатларга туры килү критерийлары нигезендә бәяләү;

Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасы) таләпләренә туры килә торган затларны конкурста катнашучылар арасыннан аларның конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын үтү нәтиҗәләрен чагыштыру юлы белән ачыклау.

## 2. КОНКУРС КОМИССИЯСЕН ФОРМАЛАШТЫРУ ҺӘМ АНЫҢ ЭШ ТӘРТИБЕ

2.1. Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы указы нигезендә Министрлыкта даими гамәлдә булган конкурс комиссиясе төзелә, аның составы Министрлык боерыгы белән раслана. Комиссия составына кертелгән вазыйфаи затларның шәхси составы үзгәртелгәндә, Министрлык боерыгы нигезендә тиешле үзгәрешләр кертелә.

2.2. Конкурс комиссиясе Рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.3. Конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итү конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан гамәлгә ашырыла. Конкурс комиссиясенең рәисе булмый торган чорда аның хокукларын һәм бурычларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясе сәркатибе конкурс комиссиясенең эшен тәэмин итә (гаризаларны терки, кабул итә, эшләрне формалаштыра, конкурста катнашучыларны исәпкә алу журналын алып бара, конкурс комиссиясе карарларын рәсмиләштерә һ.б.).

2.4. Министрлыкның конкурс комиссиясе составына министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары һәм (яки) министр тарафыннан вәкаләт бирелгән граждан хезмәткәрләре (шул исәптән дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегеннән, хокукый тәэминат бүлегеннән, вакантлы граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздырыла торган структур бүлекчәдән), Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле, Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук Министрлык гарызнамәсе буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан бәйсез экспертлар – граждан хезмәтенә бәйле мәсьәләләр буенча белгечләр сыйфатында экспертларның шәхси мәгълүматларын күрсәтмичә чакыртыла торган фәнни, мәгариф һәм башка оешмаларның вәкилләре керә.

Конкурс комиссиясе составына кертү өчен Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре кандидатуралары әлеге совет тарафыннан Министр гаризасы нигезендә тәкъдим ителә.

Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет әгъзаларының һәм бәйсез

экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясендәге барлык әгъзалар санының кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

2.5. Граждан хезмәтенең алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрелгәндә, конкурс комиссиясенең составы Россия Федерациясенең дәүләт сере турындагы законнары нигезләмәләрен исәпкә алып формалаштырыла.

2.6. Конкурс комиссиясе составы конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясарлык мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеге калмаслык итеп төзелә.

2.7. Конкурс комиссиясе утырышы граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфаларын) биләүгә карата кимендә ике кандидат булганда үткәрелә һәм, әгәр анда аның әгъзалары саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, тулы хокуклы булып санала. Конкурс комиссиясе утырышын бары тик комиссиянең граждан вазыйфаларын биләүче әгъзалары составында гына үткәрү – рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс комиссиясе:

конкурсны үткәрү шартларын регламентлый торган документларны, аны үткәрү өчен кирәкле булган методик һәм бүтән материалларны раслый;

граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) дәгъва белдерүче гражданнарга конкурсны үткәрү шартлары турында мәгълүмат җиткерә һәм консультацияли;

кандидатлардан алынган гарызнамәләр буенча конкурс документларын бирә;

кандидатлар тарафыннан граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) тапшырылган документларны тикшергәннән соң, конкурс комиссиясе конкурсның икенче этабына кертелгән кандидатлар исемлеген раслый;

кандидатларның куелган таләпләргә туры килүен бәяли;

конкурска йомгак ясау, кандидатны конкурста җиңүче итеп тану турында карар кабул итә, аны Министрлыкның кадрлар резервына кертү өчен тәкъдим итә.

2.9. Конкурс уздыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү нигезендә аның утырышта катнашкан әгъзалары тавышларының гади күпчелеге белән кабул ителә. Тавыш биргәндә конкурс комиссиясе әгъзаларының фикере «килешәм» яки «каршы» сүзләре белән белдерелә. Тавышлар тигез булган очракта, конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәл иткеч була. Конкурс комиссиясенең теләсә кайсы әгъзасы, кабул ителгән карар белән риза булмаган очракта, махсус фикерен белдерергә мөмкин, ул конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсендә теркәлә һәм конкурс комиссиясендәге әлеге әгъзаның имзасы белән беркетелә.

2.10. Конкурс комиссиясе карары кандидат үзе булмаганда кабул ителә һәм аны Министрлыктагы вакантлы граждан хезмәте вазыйфасына билгеләү (аның ризалыгы белән кадрлар резервына кертү) яисә моннан баш тарту өчен нигез булып тора.

2.11. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә (әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы) кертелә, ул

комиссия рәисе, рәис урынбасары, сәркатиб һәм утырыштка катнашкан әгъзалар тарафыннан имзалана. Шул ук вакытта конкурс комиссиясе тарафыннан граждан хезмәтенә беренче мәртәбә билгеләнгәндә гражданин өчен яки граждан хезмәткәрен Министрлыкның башка төркемдәге яки категориядәге граждан хезмәтенә күчерелгәндә сынау чорының озынлыгы буенча киңәш бирелергә мөмкин.

2.12. Конкурсны турыдан-туры оештыруны һәм уздыруны, конкурс комиссиясе эшен тәэмин итүне Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге гамәлгә ашыра.

## 3. КОНКУРСЛАРДА КАТНАШУЧЫЛАР

3.1. Конкурста катнашуга Министрлыкның вакантлы граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен кандидатларга карата тиешле таләпләргә туры килә торган һәм билгеләнгән срокта кирәкле барлык документларны тапшырган гражданнар (алга таба кандидатлар дип атала) кертелә.

Министрлыкта вакантлы граждан хезмәте вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен кандидатларга карата таләпләр (әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасы) һәм Министрлыкта вакантлы граждан хезмәте вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен кандидатлар тарафыннан тапшырыла торган документларның һәм материалларның исемлеге (әлеге Нигезләмәнең 4 нче кушымтасы) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен регламентлаучы норматив хокукый актлар нигезендә билгеләнде.

3.2. Шушы Нигезләмәнең 4 нче кушымтасында күрсәтелгән документлар аларны кабул итү турында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында игълан урнаштырылган көннән башлап 21 календарь көне эчендә дәүләт органына гражданин (граждан хезмәткәре) тарафыннан шәхсән, почта аша җибәреп яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә күрсәтелгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон рәвештә җибәрелә.

Электрон рәвештә тапшырылган белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә автоматлаштырылган рәвештә тикшерелә.

3.3. Игътибарга алынырлык сәбәпсез документларны үз вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданиннан аларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

Игътибарга алырлык сәбәп белән документларны үз вакытында тапшырмаганда, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырганда министр аларны кабул итү вакытын күчерергә хокуклы.

3.4. Тикшерү барышында гражданинның федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары нигезендә граждан хезмәтенә керүенә комачау итүче шартлар ачыкланган очракта, аңа конкурста катнаштырудан кире кагуның сәбәпләре турында Министр тарафыннан язмача рәвештә хәбәр ителә. Әгәр гражданин конкурста катнашу өчен документларны

электрон рәвештә тапшырган булса, конкурста катнаштырудан кире кагу сәбәпләре хакында хәбәрләмә аңа дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

## 4. КОНКУРСЛАРНЫ УЗДЫРУ МЕТОДИКАСЫ

4.1. Конкурсны үткәргәндә кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларына таянган, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган конкурс биремнәре һәм процедуралары кулланыла.

4.2. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү критерийлары Министрлыкта граждан хезмәте вазыйфаларына белдерелә торган квалификация таләпләренә туры китереп эшләнде.

Конкурста катнашучыларны бәяләү критерийларының үрнәк исемлеге һәм кыскача эчтәлеге шушы Нигезләмәгә карата 5 нче кушымтада китерелде.

Конкурс үткәрелә торган вазыйфаларның төркеменә һәм категориясенә карап, конкурста катнашучыларны бәяләү критерийлары үзгәртелергә мөмкин.

4.3. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу алар тарафыннан конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын үтү нәтиҗәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Нәтиҗәләр кандидатлар исемлегендәге (рейтингындагы) баллар күләме рәвешендә күрсәтелә.

4.4. Конкурс ике этапта үткәрелә.

4.4.1. Беренче этапта Министрлыкның кадрлар сәясәте бүлеге түбәндәгеләрне оештыра:

конкурс уздыру турында мәгълүмат әзерли һәм Министрлыкның рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыра, әлеге мәгълүмат түбәндәгеләрне үз эченә ала: граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасының (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасының) аталышы, әлеге вазыйфаны биләүгә дәгъва белдерүчегә карата куела торган таләпләр, граждан хезмәтен үтү шартлары, документларны кабул итү урыны һәм вакыты, аталган документларны кабул итү буенча гамәлдә булган чор, конкурсны үткәрү буенча күздә тотылган дата, аны үткәрү урыны һәм тәртибе, башка мәгълүмати материаллар. Конкурста катнашу өчен документларны кабул итү турындагы игълан һәм конкурс турындагы мәгълүмат шулай ук вакытлы басма матбугатта бастырылырга мөмкин;

гражданин (граждан хезмәткәре) тарафыннан тапшырылган документларны тикшерә;

гражданинның (граждан хезмәткәренең) квалификация таләпләренә туры килүен (һөнәри белем дәрәҗәсен, граждан хезмәте (бүтән төрле граждан хезмәтенең) стажын яки белгечлеге буенча эшләү стажын (тәҗрибәсен), әзерлек

юнәлешен, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле булган һөнәри белемнәрен һәм күнекмәләрен) тикшерә.

Конкурсның беренче этабы документларны кабул итү турында игълан урнаштырылган көннән башлана һәм 21 көннән ким булмаган чорда тәмамлана.

4.4.2. Вакантлы граждан хезмәте вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү), Министрлыкның кадрлар резервына кертү өчен кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларны тикшергәннән соң Министрлыкның кадрлар сәясәте бүлеге документлар кабул итүне тәмамлаган көннән соң җиде көнлек чорда Министрга гражданнарны (граждан хезмәткәрләрен) конкурста катнашуга кертү турында карар кабул итү яки аларны конкурста катнаштырудан нигезле баш тарту турында тәкъдим кертә.

Кандидатларның тикшерелгән документлары һәм министрлыкның кадрлар сәясәте бүлегенең тәкъдиме Министрга конкурсның икенче этабын уздыру турында карар кабул итү өчен тапшырыла.

4.4.3. Тикшерү барышында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары нигезендә гражданинның граждан хезмәтенә керүенә каршы килә торган шартлар ачыкланган очракта, аңа Министрлыкның кадрлар сәясәте бүлеге тарафыннан конкурста катнаштырудан баш тартуның сәбәпләре хакында язмача рәвештә хәбәр ителә (әлеге Нигезләмәнең 6 нчы кушымтасы).

4.4.4. Конкурста катнашуга кертелмәгән, вакантлы вазыйфаны биләү өчен дәгъва белдерүче зат бу карарга Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять белдерергә хокуклы.

4.4.5. Билгеләнгән таләпләргә туры килә торган ике һәм аннан күбрәк кандидатның булуы конкурсның беренче этабын тәмамлау шарты булып тора, бу хәл кандидатларны алга таба сайлау мөмкинлеген тәэмин итә.

Конкурсның беренче этабы тәмамлангач министр конкурсның икенче этабын уздыру датасы (катнашу өчен документлар кабул итү тәмамланганнан соң 30 календарь көне узганчы), вакыты һәм урыны турында карар кабул итә. Дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга рөхсәт рәсмиләштерелгән очракта, конкурсның икенче этабын уздыру чорын Министр билгели.

Кадрлар сәясәте бүлеге, конкурсның икенче этабы башланырга кимендә 15 календарь көне кала, Министрлыкның рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында аның уздырылу датасы, урыны һәм вакыты хакында мәгълүмат урнаштыра һәм кандидатларга тиешле хәбәрләрне язмача рәвештә, бу вакытта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрә.

4.4.6. Конкурсның икенче этабы өч төрле формада, конкурс игълан ителгән граждан хезмәте вазыйфалары төркеменә һәм категориясенә карап уздырылырга мөмкин.

А) Граждан хезмәтенең өлкән вазыйфаларына конкурс уздырылганда икенче этап түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларга анализ;

коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча анкета уздыру (вакантлы вазыйфаны биләүгә дәгъва белдерүчеләр теләге буенча);

IQ-тест уздыру

законнарны һәм рус телен белүгә (грамоталылык буенча) компьютерда тест уздыру;

Министрлыкта дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына керү) өчен дәгъва белдергән кандидатларга тест уздыру Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты раслый торган Тест уздыру методикасына туры китереп гамәлгә ашырыла;

кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын билгеләү өчен тест уздыру;

кандидатлар биләү өчен дәгъва белдерә торган вакантлы граждан хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле мәсьәләләрдә гамәли биремнәрне үтәү;

структур бүлекчәләрнең җитәкчеләре белән шәхси әңгәмәләр уздыру.

Б) Граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфаларына конкурс уздырылганда икенче этапта түбәндәгеләр үткәрелә:

кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларга анализ;

коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча анкета уздыру (вакантлы вазыйфаны биләүгә дәгъва белдерүчеләр теләге буенча);

IQ-тест уздыру;

законнар һәм грамота буенча компьютерда тест уздыру;

граждан хезмәтенең билгеле бер вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) кандидатларга тест үткәрү Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментының 2016 елның 11 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнарга тест үткәрү методикасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын билгеләү өчен тест уздыру;

кандидатлар биләү өчен дәгъва белдерә торган вакантлы граждан хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле мәсьәләләрдә гамәли биремнәрне үтәү;

структур бүлекчәләрнең җитәкчеләре, министр урынбасарлары белән шәхси әңгәмәләр уздыру.

В). Граждан хезмәтенең баш вазыйфаларына конкурсның икенче этабы түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларга анализ;

коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча анкета уздыру (вакантлы

вазыйфаны биләүгә дәгъва белдерүчеләр теләге буенча);

IQ-тест уздыру;

законнарны һәм рус телен белүгә (грамоталылык буенча) компьютерда тест уздыру;

кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын билгеләү өчен тест уздыру;

граждан хезмәтенең билгеле бер вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) кандидатларга тест үткәрү Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментының 2016 елның 11 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнарга тест үткәрү методикасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

кандидатлар биләү өчен дәгъва белдерә торган вакантлы граждан хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле мәсьәләләрдә гамәли биремнәрне үтәү;

структур бүлекчәләрнең җитәкчеләре, министр урынбасарлары белән шәхси әңгәмәләр уздыру.

4.4.7. Кандидатларга тест сынаулары компьютер формасында уздырыла. Конкурс комиссиясе дәгъва белдерүчеләргә тест сынаулары өчен сораулар исемлеген төзи, шулай ук дөрес булмаган җавапларның чик исәбен (яисә процентын) раслый. Дөрес булмаган җавапларның рөхсәт ителгән исәбе 25 проценттан артык була алмый.

Сораулар исемлеге гомуми танышу өчен мөмкин булырга тиеш. Тест сораулар исемлеге нигезендә төзелә һәм конкурста катнашучының түбәндәгеләрне белүен тикшерүне тәэмин итәргә тиеш:

Россия Федерациясе Конституциясен һәм Татарстан Республикасы Конституциясен;

Федераль законнарны һәм Татарстан Республикасы законнарын;

Дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын; «Мәгариф турында».

Рус телен белү;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы турында нигезләмәне;

Тестта иң күбе 50 сорау булырга тиеш.

Дөрес җаваплар тигез санда булганда, катнашучыларга җавап бирү өчен вакыты билгеләнеп, өстәмә тестлар бирелә.

4.4.8. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләгәндә конкурс комиссиясе граждан хезмәте вазыйфасына карата тиешле квалификация таләпләреннән һәм әлеге вазыйфа буенча вазыйфаи регламентның башка нигезләмәләреннән, шулай ук әлеге Нигезләмәдә һәм дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән башка нигезләмәләрдән чыгып эш итә.

4.4.9. Дәгъва белдерүчеләрнең профессиональ һәм шәхси сыйфатларын

конкурс комиссиясе әгъзалары кадрлар сәясәте бүлеге тарафыннан һәр конкурска әзерләнә торган бәяләү кәгазьләрендә билгели.

4.4.10. Конкурс башланыр алдыннан турыдан-туры конкурс комиссиясе утырышына рәислек итүче зат конкурс комиссиясе әгъзаларына аны уздыру, билгеләр кую тәртибе турында, конкурс комиссиясе әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары турында инструктаж уздыра.

4.4.11. Конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы конкурс комиссиясе сәркатибеннән конкурстагы барлык катнашучыларга бәяләү кәгазьләрен ала һәм тиешле баллар куя. Һәр бәяләү кәгазендә гомуми баллар исәбен куйганнан соң, конкурс комиссиясе әгъзасы бәяләү кәгазьләрен имзалый һәм аларны конкурс комиссиясе сәркатибенә тапшыра.

4.4.12. Бәяләү кәгазьләре нигезендә конкурс комиссиясе сәркатибе конкурста һәр катнашучы алган нәтиҗә балларын куша.

Бәяләү кәгазенә төзәтмәләр кертү рөхсәт ителми.

Кандидатларны бәяләүнең ахыргы нәтиҗәләре анкетага (әлеге Нигезләмәнең 8 нче кушымтасы) кертелә.

4.5. Икенче этапның нәтиҗәсе һәм бер үк вакытта конкурсның йомгаклау нәтиҗәләре булып граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү буенча кандидатларның конкурс комиссияләре тарафыннан әзерләнгән рейтинглары тора.

Конкурс йомгакларын ясау һәм граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен кандидат турында карар кабул итү нигезләре булып түбәндәгеләр тора:

бәяләү критерийлары буенча кандидатлар тарафыннан барлык конкурс процедураларын алу нәтиҗәләре буенча тупланган баллар суммалары;

кандидатлар шундагы вазыйфага дәгъва белдерә торган структур бүлекчә җитәкчеләренең кандидатлар белән әңгәмә (әңгәмәләр) уздыру йомгаклары буенча фикере (Министрлык җитәкчелегенең фикере).

Конкурс комиссиясе конкурста җиңүче турында карарлар, шулай ук Министрлыкның кадрлар резервына тәкъдим ителгән кандидатлар исемлекләрен раслый.

4.6. Конкурс уздыру нәтиҗәсендә граждан хезмәтенең аны биләү өчен конкурс игълан ителгән вакантлы вазыйфасы буенча барлык кирәкле таләпләргә җавап бирә торган кандидатлар ачыкланган очракта, конкурс комиссиясе өстәмә конкурс сынауларын үткәрү турында карар кабул итәргә яки яңа конкурс уздыру турында тәкъдим кертергә хокуклы.

4.7. Министр яңа конкурс уздыру турында яки конкурста катнашкан, вакантлы вазыйфаны биләү өчен белдерелә торган таләпләргә аеруча туры килә торган һәм иң күп баллар санын туплаган затны вакантлы граждан хезмәте вазыйфасына билгеләү (кадрлар резервына кертү) турында карар кабул итә.

4.8. Әгәр конкурста катнашучы ике яки аннан күбрәк затлар тигез сандагы балларны тупласа, конкурс комиссиясе рәисенең фикере хәл иткеч була.

4.9. Конкурс уздыру нәтиҗәләре буенча беркетмә рәсмиләштерелә, аңа конкурс комиссиясе утырышында рәис, сәркатиб һәм конкурс комиссиясенең конкурс комиссиясе утырышында катнашкан әгъзалары кул куя.

4.10. Конкурс нәтиҗәләре нигезендә конкурста җиңүчене дәүләт граждан

хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләү турында Министр боерыгы чыгарыла һәм аның белән хезмәт контракты төзелә.

Граждан хезмәткәрен (гражданинны) – конкурста җиңүчене кадрлар резервына кертү, тиешле язуны граждан хезмәткәренең шәхси эшләренә һәм граждан хезмәткәренең хезмәт эшчәнлеген раслый торган бүтән документларга кертеп, Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Бу вакытта вазыйфалар номенклатурасы нигезендә, конкурста җиңүчене вазыйфага билгеләү өчен тәкъдим иткәндә, Министрга мәҗбүри тәртиптә конкурс комиссиясе тарафыннан мондый карарны кабул итүгә нигез булып хезмәт иткән конкурс комиссиясе карары һәм материаллар кертелә.

4.11. Вакантлы граждан хезмәте вазыйфасына билгеләүдән кандидатны кире кагу очрагында аңа Министрлыкның кадрлар резервыннан тиешле вазыйфа тәкъдим ителергә мөмкин.

4.12. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидат конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять белдерергә хокуклы.

4.13. Конкурс нәтиҗәләре хакында хәбәрләр ул тәмамланганнан соң 7 көнлек чорда кандидатларга язмача рәвештә, бу вакытта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат шул ук чорла Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

4.14. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) дәгъва белдергән, ләкин конкурста катнашуга кертелмәгән кандидатларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары язма гаризалары буенча конкурс тәмамланган көннән соң өч ел дәвамында аларга кайтарып бирелергә мөмкин. Әлеге чор тәмамланганчыга кадәр документлар Министрлык архивында саклана, аннан соң юкка чыгарылырга тиеш. Конкурста катнашу өчен электрон рәвештә тапшырылган документлар өч ел саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш.

4.15. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрелгән урынга бару һәм кайту, торак урынга түләү, яшәү, элемтә чаралары хезмәтләреннән файдалану һәм башкасы) кандидатлар тарафыннан үз акчалары хисабыннан түләнә.

**Татарстан Республикасы**
**Мәгариф һәм фән**
**министрлыгының 2016 елның 22**
**ноябрендәге под-2245/16 номерлы**

**боерыгы белән расланган**
**нигезләмәгә 1 нче кушымта**

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары –
